ҮЗГӘРЕШ ҖИЛЕ
Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләренә тариф бәяләрен үзгәртү ни өчен кирәк?
> 2

МАТБУГАТ КӨЧЕ
Фәрит Мөхәммәтшин журналистларны һөнәри бәйрәмнәре белән котлады
> 2

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК...
Укучыларыбызның уй-фикерләре, истәлек-хатирәләре
> 3



ШАГЫЙРЬНЕҢ КАЙТУЫ
Равил Фәйзуллинга туган ягында музей ачылды
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 5 (28972) | Шимбә | 14 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Вазгыять

САКЛАНУ АРТЫК ТҮГЕЛ

БЕЛГЕЧЛӘР, ОРВИ ҺӘМ ГРИПП БЕЛӘН АВЫРУЧЫЛАР КИМЕСӘ ДӘ, ИРКЕНӘЙМӘСКӘ КУША

Өстә – кышкы куртка, кочакта – кап-кайнар батарея. Әмма бу гына җылытмый. Гриппның төп билгесе дә шул – эчкә җылы кермәү икән. Хезмәттәшебез Динә Гыйлаҗиева бу көннәрдә вирус белән көрәшеп, шундый фикергә килгән. «Болай ук авырган юк иде әле», – ди ул хәзер.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Тамак, борын, баш...

– Атна башында нинди кыяфәттә булуымны күрдең инде. Кәбестә сыман киенеп, батарея кочаклап утырудан башланды бу хәл. Тик болай эшләү аз гына да җылытмады. Эчкә җылы кермәү гриппның төп билгесе икән. Иртүк хәлсезлек сизгән идем. Әмма аны түбән кан басымына сылтадым. Эштә исә калтыратырга тотынды. Бу бит әле 40 градуслы салкын көннәрнең берсе дә иде. Язма әзерләгән арада да батарея белән кочаклашып алам шулай. Төш вакытына температура күтәрелә башлады. Өйгә кайткач, тамак авыртырга тотынды. Төкерек тә йотып булмаслык дәрәҗәдә! Табиб чакырттык, дарулар язды. Әмма ул авыртуны бернинди май, спрей, чайкау, халык медицинасы да басарлык түгел иде. Әйтерсең лә тамакта ниндидер зур шеш урын алган. Температура да бик авырдан төште. Көннәр буе йокладым гына диярлек. Ашау-эчү турында әйтмим дә инде, шуңа күрә, йокламыйча, тагын нишлисең? Авыз кибә, суны көч-хәл белән йотасың... Калтырану өч көн дәвам итте әле. Башкалар бер кат киемнән йөргәндә, мин юрган астында, әллә ничә кат киемнән дә туңып яттым. Икенче көнгә колак та сызлый башламасынмы?! Тамак белән бергәләшеп тотынды болар! Температура да өч көн төшмәде. Тамак авыртуы дүртенче көнгә генә бирешә башлады. Аннары инде колак сызлавы да чигенде. Кичә беренче тапкыр чәй эчтем! Төкерек йота алу да зур бәхет икән бит! – дип сөйләде хезмәттәшебез.

«Татар радиосы» ди-джее Илүзә Касыймова, чирне аяк өстендә уздырып җибәрдем, ди. Ә менә авылда яшәүче әти-әнисе, сеңлесе, энесе һәм башка туганнарына чир ныклап ябышкан булган.

– Бик сәер булды ул. Декабрь азагында тамак һәм баш авыртты. Температура күтәрелмәде. Аякта йөреп уздырдым мин аны. Өйдәгеләр шәпләп авырды. Хәлләре мөшкел булды. Кайберәүләренең чирләре 1–2 атнага кадәр сузылды. Белмим, безнең әллә һөнәребезгә бәйле рәвештә иммунитетыбыз бармы, 2–3 көндә хәл керде миңа. Сырганаклы, мәтрүшкәле, лимонлы, баллы чәйләр дә булышмый калмагандыр. Әлбәттә, дарулар да эчтем, – дип сөйләде ул.

Сер түгел, Динә һәм Илүзә кичергәннәрне бу арада күпләр күрде. Вирус чигенергә уйлыймы икән соң? Әллә инде тагын да куркынычрак булып, кеше сәламәтлегенә күбрәк зыян салырга җыенамы? Белгечләр белән кабат вазгыятькә күз салдык.

Онытырлык түгел

Россиядә грипп белән авыру дәрәҗәсе үссә дә, әллә ни зур булмаячак. Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова илдәге вазгыятькә шундый бәя бирде.

Россиянең баш санитар табибы әйтүенчә, авыручыларның 2022 ел азагында күзәтелгән кимүенә әллә ни әһәмият биреп булмый. Ник дигәндә, кайбер сырхаулар медицина ярдәменә мөрәҗәгать итмәгән, өйдә генә дәваланган, димәк, бу очраклар теркәлмәгән. Яңа ел ялларында да шулай ук булган.

– Соңгы көннәрдә чирләүчеләрнең артуын күзәтсәк тә, ул әллә ни куркыныч түгел. Бу – нигездә, өйдә генә калып, хәзер инде медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итүчеләр, – дип аңлатты Анна Попова.

Белгеч аңлатканча, 2009 елгы H1N1 гриппына алмашка B штаммы килгән. Анна Попова сүзләренчә, вирус организм өчен үзе белән бронхит һәм үпкә ялкынсынуы кебек «күчтәнәч»ләр дә алып килә. «Грипп – тын юллары вирусы. Шуңа күрә аннан коронавирустан саклаган чараларны кулланып сакланырга мөмкин», – дип искәртте белгеч.

Сан теле белән әйткәндә, Россиядә ОРВИ һәм грипп белән чирләү очраклары 52 процентка кимегән. Гомумән, чирләр өлешендә грипп өстенлек итә. Респиратор инфекцияләргә аның 83 проценты туры килә. Шуңа күрә Роспотребнадзор төбәкләргә вазгыятьне күз уңыннан югалтмаска һәм санитар-эпидемиологик чараларны дәвам иттерергә куша.

Ахыры 2 нче биттә >>

7 КИҢӘШ

1. Халык күп йөргән урыннарда йөрмәскә. Төчкергәндә вирус – 3 метрга, йөткергәндә 4 метрга кадәр оча. Аннан качып котылу җиңел түгел.
2. Өйгә кайтуга, борынны юдырыгыз.
3. Бина, бүлмә эчендә һаваны дымландырып торырга кирәк.
4. С витамины кергән ризыклар ашарга киңәш ителә.
5. Кулларны ешрак юарга, антисептик кулланырга.
6. Битлек киеп йөрергә.
7. Ашарга ризык әзерләгәндә, сарымсак һәм суган салырга онытмагыз.

Тик торса да, куркыныч

Юл кырыенда калдырылган машиналар зур куркыныч тудыра. Дәүләт автомобиль инспекциясе мәгълүматларына караганда, соңгы биш ел эчендә шул сәбәпле 519 фаҗига килеп чыккан. 52 кеше һәлак булган, 672се җәрәхәтләнгән яки имгәнгән.

Мондый автомобильләр бигрәк тә шәһәр читендәге юлларда куркыныч. Әйтик, узган елның октябрендә Әлмәт районында Казан – Оренбург юлында җиңел автомобиль караңгыда, буранда юл буенда туктап калган «КамАЗ»га килеп бәрелгән. Рульдәге кыз шундук һәлак булган. Кызганычка, мондый фаҗигаләр әледән-әле кабатланып тора.

Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе башлыгы Рөстәм Гарипов кисәткәнчә, юл читендә туктап калырга туры килгәндә, иң элек авария сигнализациясен кабызып куярга кирәк. Юлда яки кырыйда басып торучының «янып торган» полосалы куртка яки жилет кигән булуы мөһим. Инде килеп, транспортны куркынычсызрак урынга күчерү чарасын күрергә кирәк. Шулай ук 112 хезмәтенә шалтыратып, техник ярдәм чакыртырга мөмкин. Махсус хезмәтләр килгәнче, машина яныннан китмәү шарт.

Кредитлы тормыш

Россиядә яшәүчеләр узган елда барлыгы 27 триллион сумнан артыграк күләмдә кредит алган. Узган елдагыга (2,5 триллион сум) караганда 10 процентка диярлек зуррак сан бу. «Известия» хәбәр иткәнчә, кредитның 80 проценттан күбрәге – ипотека. 2023 елның башына куллану кредиты күләме чама белән 12 триллион сум тәшкил иткән.

2022 елның март – апрель айларында кредит алучылар күпкә кимегән. Әмма җәен һәм көзен Үзәк банкның төп ставкасы киму сәбәпле, ихтыяҗ яңадан пәйда булып, кредит элекке күләмдә бирелә башлаган.

Сүз уңаеннан, Татарстан куллану кредитлары күләме ягыннан илдә алдынгы сафларда бара. Узган елның өченче кварталында республикада яшәүчеләр барлыгы 28,1 миллиард сумлык кредит алган.

Менә шундый таныклык

Хәзер автоинспекторларга «права»ның һәм транспортны теркәү турында таныклыкның цифрлы күчермәсен генә дә күрсәтергә мөмкин. «Госуслуги Авто» мобиль кушымтасында шундый сервис булдырылган.

«МВД Медиа» хәбәренә караганда, кушымта 2021 елдан бирле эшли. Аның ярдәмендә, полиция хезмәткәрен чакыртмыйча гына, евроберкетмә нигезендә, җитди булмаган аварияне рәсмиләштерергә, транспорт чарасын теркәү, машина йөртүче таныклыгын алыштыру өчен язылырга, шулай ук юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штраф түләргә мөмкин.

Хәзер машина йөртүче таныклыгын да мобиль кушымта аша гына автоинспекторга күрсәтү мөмкинлеге ачылган. ЮХИДИ хезмәткәре аны мобиль җайланма (анда QR кодны укый торган программа урнаштырылган) ярдәмендә тикшерә. Таныклыкны, кушымта ярдәмендә, интернет тотмаган урыннарда да күрсәтеп булачак.

«Госуслуги Авто» кушымтасыннан хәзер 2,5 миллионнан артыграк кеше файдалана икән инде. Шул ук вакытта, Эчке эшләр министрлыгында искәртеп үтелгәнчә, йөртүчеләр, элеккечә үк, кәгазь таныклыкларын да үзләре белән йөртергә тиеш.

Вируслы булмасын

Узган ел шәхси затларга карата киберһөҗүмнәр саны 44 процентка арткан. Хакерлар ешрак социаль инженерия ысулын кулланып эш итә башлаган. Әйтик, ялган сайтлар булдыру, социаль челтәрләр аша вируслы хатлар, сылтамалар җибәрү һәм башка ысуллар. Кырыгалдарлар 93 процент очракта шул юлларны сайлый икән. «Positive Technologies» хисабында мәгълүмати куркынычсызлык турында шулай диелгән.

Роскомнадзор хәбәр итүенчә, узган ел башында кешеләрнең шәхси мәгълүматлары сакланган дистәләгән зур шәхси мәгълүмат югалуы теркәлгән (аларда халыкның 230 миллионнан артык шәхси мәгълүматы булган). 2022 елда кырыгалдарлар булдырган 11900ләп сайтны юк иткәннәр.

Быел исә хакерлар популяр социаль челтәрләрдәге сәхифәләргә аеруча һөҗүм итәр дип көтелә. Шуңа күрә белгечләр иҗтимагый-мәдәни чаралар, фильм-сериаллар, спорт ярышларына бәйле теге яки бу тәкъдимнәргә сак карарга киңәш итә. Бу да мошенникларның алдалау ысулы булырга мөмкин.

Яшәргә өйрәнәбез

Киләчәк һөнәрләре

«Нинди һөнәргә өйрәнсәң, әйбәтрәк булыр икән?» дигән сорау мәктәпне тәмамлаучыларны гына түгел, эшен алмаштырырга теләүчеләрне дә борчый. Кайсыдыр һөнәрләргә ихтыяҗ кими, ә кайберләренә, киресенчә, арта. Шул ук вакытта беркайчан да әһәмиятен җуймаган мәңгелек һөнәрләр дә бар.

Белгечләр әйтүенчә, озакламый кассирлар, банк операционистлары, такси йөртүче, кече хисапчы, сакчы кебек аз квалификацияле белгечләргә эш табу кыен булачак. Чыннан да, үзебез дә шәһәр кибетләрендә, гадәти касса янына килеп басмыйча, товар өчен «самообслуживание» кассасында гына түләүгә күнегеп киләбез, интернет-кибетләргә рәхәтләнеп «йөрибез», юлларда пилотсыз таксиларны күреп торабыз. Телибезме-теләмибезме, хезмәт күрсәтү өлкәсенең автоматлашуы кайбер һөнәрләрне әкренләп юкка чыгарачак.

Нинди белгечләргә ихтыяҗ зур? Беренчедән, телебездән төшмәгән **IT белгечләр**гә. Аларны зур компанияләргә чакырып торалар, хәтта кайвакыт үзләре куйган эш шартлары (әйтик, хезмәт хакы күләме буенча) белән дә ризалашалар. Шуларның берничәсен атап үтик.

Ясалма акыл буенча инженер. Ясалма интеллект буенча эшләүче программист бу. Хәзер күп кенә компанияләрдә әлеге технология киң кулланыла. Иң гади мисалларның берсе – «Яндекс. Навигатор» мобиль кушымтасы. Аның ярдәмендә без юл шартларын смартфон аша гына бәяләп, юл йөрүне бермә-бер җиңеләйтәбез. Белгеч ясалма акылны үз бурычын башкарырга өйрәтә.

SMM-менеджер да – бик кирәкле һөнәр. Хәзер һәрбер газета-журналның, кибет, матурлык салоны, һәр производствоның интернеттагы сайты гына түгел, социаль челтәрләрдә дә аккаунтлары бар. Бу сәхифәләрне алып бару өчен әзерлекле кешеләр таләп ителә. Алар халык өчен кирәкле мәгълүматларны бастыра, язылучылар белән элемтәгә керә, бәйгеләр оештыра. Шулай итеп, товарга карата кызыксыну тудыра, интернет аша аны сату күләмен арттыруга этәргеч бирә.

Мәгълүмати иминлек өлкәсендә белгеч. Компьютердан гади файдаланучылар гына түгел, тулы бер оешма-предприятиеләр хакерлардан саклануга мохтаҗ. Әлеге белгечнең бурычы – компьютер программасының «йомшак» якларын ачыклау һәм нәтиҗәле саклау системасын булдыру.

Болар – яңа һөнәрләр. Ә классик һөнәрләр арасында, **табиб, укытучыдан тыш, косметолог, инженер, логист** (товар ташуның иң нәтиҗәле юлларын эзләп табучылар), **курьер**ларга ихтыяҗ көннән-көн арта.

Иҗади һөнәрләргә килгәндә, **арт-менеджер**ны (сәнгать белән бизнес арасында эшләүче белгечләр) атап үтәргә мөмкин. Ул проектлар эшли, аларның бюджетын исәпләп чыгара, проектта катнашучылар белән элемтәләр кора. Аннан килеп, хәзер **подкаст эшләүчеләр**гә (аудиофайллар яздырып, аларны керем чыганагына әйләндерүчеләр) дә зур мөмкинлекләр тудырыла.

Сүзгә-сүз

Инна СВЯТЕНКО, Федерация Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе:

Эшсезлекне һәм ярлылыкны киметергә «Халыкны эш белән тәэмин итү турында»гы законга төзәтмәләр кертү мөмкинлек бирәчәк. Илдәге һәр гражданның, матди яктан гына түгел, үзенең психологик, эмоциональ һәм белем үзенчәлекләрен исәпкә алып башкара алган эш табуы бик мөһим.

(«Российская газета»дан)

РОССИЯДӘ – МАТБУГАТ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россия халкыннан матбугатка мөнәсәбәте турында сорашкан. Шунысы да бар: басма матбугатны иң күп укучылар Урал федераль округында икән.

14% >> даими рәвештә кәгазь матбугат белән таныша

62% >> онлайн матбугат чаралары белән таныша

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Динсез дөнья сансыз

Иртәгә – Бөтендөнья дин көне. Кешелек тарихы ул – сугышлар тарихы гына түгел, диннәр тарихы да. Кеше заты һәрчак нәрсәгә булса да ышанган. Ышанырга мәҗбүр булган. Чөнки аны урап алган тирәлек, табигатьтәге күренешләр нинди дә булса аңлату сораган. Нindидер югары көч, югары акыл юк икән, ул урман-кырлар, таулар, елга-диңгезләрне, күп төрле җәнлекләрне, үсемлекләрне, җимеш агачларын кем барлыкка китергән соң? Үзеннән-үзе ярала алмый ич алар. Борынгы кешенең мантыйгы, ихтимал, шундыйрак булгандыр.

Дин булмаса, бүгенге дөнья нindирәк булыр иде икән? Ихтимал, начаррак. Диннәр йогынтысы кимеп барган хәзерге чорда да алар бик күпләр өчен маяк, начарны яхшыдан аерып күрсәтүче хөкемче, модератор ролендә кала әле. Яшерен-батырын түгел, диннәр бүгенге технологияле заманга җайлашты. Һәм бер үк вакытта элекке дәверләрдә булган көчен дә җуйды кебек. Бу күренештә тискәре һәм уңай яклар бар. Уңай як шул: көчле, йогынтылы чорларда диннәрнең роле гел генә саваплы булмаган бит.

Әлбәттә, мәҗүсилек дәверләре, мәсәлән, шул ук антик чор булган. Диңгезнең – үз алласы, җир астының – үзенеке. Әле тагын уңыш алласы, тимерчелекнеке, гаиләнеке – борынгы грек һәм римлыларның дистәләгән аллаларының һәрберсе үз юнәлеше өчен җавап тоткан. Тик нәрсәдер, кемнәрдер артык күп икән, аның кадере зурдан булмый шул инде. Классик, дөньяви диннәр тантанасы чорындагыдан аермалы буларак, шул ук греклар, аллаларга ышанса да, алардан бер дә курыкмаган. Ул гынамы, алар турында кырыкмаса-кырык төрле миф, хәтта мәзәкләр чыгарган. Кырын ятып, вино эчкән, күңел ачкан чакларда Зевс һәм аның хатыннары хакында көлешә-көлешә, кем әйтмешли, хагын да, нахагын да сипкән алар. Тыюлар бөтенләй дә күзәтелмәгән.

Төп дөньяви диннәрнең берсе булган нәсарилык, ягъни христианлык яралгач, вазгыять, әлбәттә, нык үзгәргән. Яңа дин белән дүрт гасыр буе көрәшкән Рим, ахыр килеп, аны үзенең дәүләт дине иткәч бигрәк тә. Аллаһы бары берәү. Аның тәгълиматына, ул кушканнарга бәндә сүзсез буйсынырга, ул кушканча гына яшәргә тиеш. Ягъни дин кешенең тормыш-көнкүрешенә үтә, аны регламентка сала башлый. Әлбәттә, чама белгәндә, бу гамәлдә бер начарлык та юк. Ләкин… Чама бөтенләй калмаган Урта гасырларда шул ук Европада инквизиция дип аталган чиркәү судының нинди җинаятьләргә барганы күпләргә мәгълүм. Яла аркасында сихерче келәймәсе алганнардан башлап, дин әйткәнчә яшәмәүче, хәтта уйламаучыларны, шул исәптән «Җир Кояш тирәли әйләнә» дигән инанудан баш тартмаган Джордано Бруноганы чаклы, күп сөйләшеп тормастан, баганага бәйләп, утта яндырганнарын беләбез. Ә бит барысы да дин, Алла исеме белән башкарылган.

Нәсари диненнән җиде гасырга соңрак яралган исламны, аның элекке чорларын да ул яктан бөтенләй үк гөнаһсыз дип әйтеп булмый. Безнең дин очрагында да бәндәне яхшы итәргә теләп, начарга, дини диктатурага кереп киткән чорлар булмаган түгел, булган. Мөхәммәт пәйгамбәр, язуларынча, төрле рәхимсезлекне, кешене терелэй яндыру кебек коточкыч кыргыйлыкларны тыйган тәкъдирдә дә. Дөньяви диннәрнең иң өлкәне иудаизмда да, исламда да җәзаларның шактый дәһшәтлеләре – мәсәлән, иренә хыянәт иткән хатын-кызны ташлар белән сугып үтерү гадәте булганы билгеле. Цивилизация барып җитмәгән тарафларда андый вәхшилек бүген дә бар, диләр. Моның ише хәлләр – җиңелрәк җәза кулланасы урында, урлашкан өчен кулны кисү, үзара якынлык өчен ир-атларны үлемгә хөкем итү кебек үтә кырыс җәзалар динне, миңа калса, бик үк бизәми.

Дөнья, сирәк тарафларны исәпләмәгәндә, Урта гасырлардан, шөкер, чыкты. Әйткәнебезчә, заманнар белән бергә диннәр дә үзгәрде. Христиан диненең соңрак олы бер тармагы булып киткән протестантлык тумаса, Европа бүгенге Европа була алыр иде микән? Юктыр. Хезмәтне, хәләл көч белән баюны культ дәрәҗәсенә күтәргән, дини кануннарга аек акыл белән караган, күңел ачулы, исерткеч эчемлекле тормышны хупламаган шул дингә кереп киткән дәүләтләрдә бүген иң югары тормыш сыйфаты. Протестант дине үзе белән янәшә яшәгән католикларны да үзгәрткән. Тик Испания, Португалиянең, тормыш дәрәҗәсе дигәндә, күпчелек халкы протестант динендә торган Швеция белән Германияне уза алганы юк әле. Әлбәттә, бүген Европа илләрендә тоташ диндарлык күзәтелми. Тик Реформация чоры продукты булган, XVI гасырда яралган без әйткән дин, аннан соңгы өч йөз ел дәвамында – йогынтысы көчле чакта – үз эшен шәпләп башкарып чыккан, дияргә мөмкин.

Византиядә яралып, Россиягә күчкән, безнең тарафларда ислам белән янәшә яшәгән православие дә – христиан диненең бер тармагы, состав өлеше. Гәрчә католиклар белән протестантларның кайсылары аңа секта дип, өстән аска караса да. Әлеге диннең дә яши-яши үзгәрешләр кичергәнлеген, Россиядәге христиан диненә унификация керткән Никон реформаларын беләбез. Әмма реформаның төрлесе була. Үзләрен иске дин вәкилләре (старообрядцы, староверы) дип атаган, XVII гасырдан соң да элекке кыйблаларына тугры калган христианнарның, мәсәлән, хезмәткә мөкиббәнлеге, чиста-пөхтәлеге, спиртлы эчемлекләргә сак мөнәсәбәте аларны протестантларга охшаш итә. Күптән бер язганымча, ул дин вәкилләре арасында иганәчелек бик популяр булган. Шул ук Казан староверлары кылган изге эшләр, алар төзеткән биналар турында язсам, сүз озакка китәчәк. Фикеремне беркемгә дә көчләп такмыйча, шуны сорыйсым килә: Никон реформалары Россия үсешендә күпмедер кире роль уйнамады микән?

Бик күп төрки халыклар белән бергә без – татарлар да үз иткән ислам диненә кайтыйк. Башка төп диннәр белән чагыштырганда мин аны көчле һәм нәтиҗәлерәк дин дияр идем. Башка конфессия вәкилләре кими барганда, яисә артмаганда мөселман өммәтендәге кешеләр күбәюдә. Безнең дин тарафдарлары дөнья халкының чирегенә якынын (23 процент) тәшкил итә. Исламда, башкалар белән чагыштырганда, дингә ярты-йорты ышанучылар шактый аз. Динебез, көчен җуймастан, шактый уңай үзгәрешләр кичерде. Элекке заманнардагыча җыр-музыка, рәсем-сын сәнгатен тыю, инкарь итү бүген юк хисабында. Исламның радикаль агымнары да халыкта теләктәшлек тапмый. Дәүләт диннән аерылмаган ислам илләре дә бүген цивилизацияле юлда.

Диннәр бүген элекке чорларга караганда да ныграк кирәк. Ни генә әйтмә, бер-берсеннән аерылган җәһәттә дә алар барысы да гомумкешелек кыйммәтләре – әхлак, шәфкать, миһербанлык яклы бит.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Уфада Башкортстанның Беренче Президенты Мортаза Рәхимов белән хушлаштылар. Республиканың элеккеге җитәкчесен соңгы юлга озатырга Россия Президенты Владимир Путин да килде.

Билгеле булганча, Мортаза Рәхимов чәршәмбе көнне, озакка сузылган авырудан соң, 88 яшендә вафат булды. Матәм чарасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә катнашты. «Башкорт халкының бөек улын, күренекле дәүләт эшлеклесен озатабыз. Шушы катлаулы чорның символы булган кеше белән саубуллашабыз», – диде Башкортстан башлыгы Радий Хәбиров үз чыгышында.

Рөстәм Миңнеханов бөтен Татарстан халкы һәм шәхсән үз исеменнән тирән кайгы уртаклашу сүзләрен җиткерде.

– Башкортстанның Беренче Президентын соңгы юлга озатабыз. Ул безнең өчен якын кеше иде. Бу – бөтен ил өчен зур югалту. Мортаза Рәхимов Минтимер Шәймиев белән дус булды һәм бу безнең тыгыз элемтәләрдә дә чагылыш тапты, – диде Татарстан Президенты.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Мортаза Рәхимов үз халкы өчен бөтен көчен һәм белемен биргән. «Мин аңа һәрвакыт зур хөрмәт белән карадым. Мортаза Рәхимовның якты истәлеге безнең йөрәкләрдә сакланачак», – диде ул.

Минтимер Шәймиев тә Башкортстанның Беренче Президентына бәйле истәлекләре белән уртаклашты.

– Без Мортаза Гобәйдулла улы белән ярышып эшләдек, көнләштек тә, бәхәсләштек тә, әмма һәрвакыт уртак тел таба идек. Ә аның белән дә, минем белән дә уртак тел табу җиңел булмады, – диде ул.

Минтимер Шәймиев искәртеп үткәнчә, татарлар һәм башкортлар – Россия үсешенә зур сәяси һәм икътисадый өлеш керткән тугандаш халыклар. «Ул тарихта яхшы эз калдырды, – диде Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Мортаза Рәхимов турында. – Күп нәрсәгә иреште. Россия үсешенә сәяси яктан да, хуҗалык эшләрендә дә җитди өлеш кертте. Барысы да җиңел бирелмәде, үзгәртеп кору еллары да булды. Иң мөһиме, Татарстан һәм Башкортстан җитәкчелеге бу күркәм традицияләрне дәвам иттерүгә иреште һәм бу хәзер дә шулай».

ТҮЛӘҮ НИГЕЗЛЕ БУЛСЫН

Нәтиҗә

Ут янсын, су аксын, ә чүпне вакытында чыгарсыннар, дисәң, түләргә туры киләчәк. Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетының еллык коллегиясендә халык арасында аңлату эшләрен арттырырга киңәш иттеләр. Бәяләр кыйммәтләнсә дә, тормыш дәвам итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чарада катнашкан Россия Монополияләргә каршы федераль хезмәт җитәкчесе урынбасары Виталий Королев республика тарифчыларының эшен югары бәяләде. Аңлашыла ки, коллегиядә былтыр коммуналь хезмәтләргә тарифларның бер ел эчендә ике тапкыр артуы турында сүз берничә тапкыр күтәрелде. Виталий Королев халыкка барысын да бәйнә-бәйнә аңлатырга киңәш итте.

Бу айда декабрь өчен түләү кәгазьләрен алучылар, яңа бәяләрне күреп, аптырашта калды. Ут һәм су кесәгә суга! Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев тынычландырырга да ашыкты: моннан ары коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр 2024 елның җәендә генә артачак. Шулай итеп, ел ярым дәвамында кыйммәтләнмәячәк. Бу мәсьәләдә халык белән даими эш алып барылуына да басым ясады ул. Узган ел, мәсәлән, Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетына килеп ирешкән мөрәҗәгатьләрнең 30 проценты диярлек коммуналь хезмәтләр өчен бәяләргә бәйле булган. Икенче урында – су мәсьәләсе (20 процент). Халык арасында ут белән тәэмин итү дә еш борчу уята (19 процент).

Александр Груничев әйтүенчә, халыкка күрсәтелгән хезмәтләрнең бәясе аның сыйфатына туры килергә дә тиеш. «Мәсәлән, Бөгелмәдә яшәүчеләрнең күбесе өйдәге торбаларның бер караганда – җылы, икенче караганда суык булуыннан зарланды. Моңа бәйле кыенлыклар булуын җылылык белән тәэмин итүче оешма да раслады. Тик менә коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазендә бу берничек тә чагылыш тапмаган. Әлеге мәсьәлә контрольгә алынды. Халыкка килмәгән җылылык өчен акчаны кире кайтарачаклар», – диде Александр Груничев. Ул тагын бер кат шуны да искә төшерде: коммуналь хезмәтләрнең сыйфаты начар, алар вакытында күрсәтелмәгән яки исәпләүләргә бәйле шикаятьләр булган очракта, иң элек коммуналь хезмәтләрне күрсәтүчегә, ә алардан тиешле җавап булмаса яки ул канәгатьләндермәсә, Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетына яки Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә субсидия дә каралган. Былтыр республикада яшәүче 72927 гаилә дәүләттән 1 миллион 70 мең сумлык ярдәм алган. Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидлар, хезмәт ветераннары кебек ташламага ия булучыларга 4 миллион 340 мең сумлык субсидия түләнгән.

Тарифларны арттырмыйча да булмый. Коллегиядә чыгыш ясаган Питрәч районы башлыгы Илһам Кашапов әйтүенчә, соңгы ун елда районда яшәүчеләр саны ике тапкыр арткан. «Бүген Питрәчтә 62 мең кеше теркәлгән, яшәүчеләр саны исә тагын да күбрәк. Былтыр төзелеш планын 120 процентка үтәдек. Барлыгы 239 мең квадрат метр торакны кулланышка тапшырдык. Димәк, инженер челтәрләрен дә даими карап, төзәтеп торырга кирәк. Бу исә – чыгымнар дигән сүз. Районда, мәсәлән, чиста суга тариф 26 сум 24 тиен тәшкил итә. Хезмәт күрсәтүче оешмаларга бу ертыкларны ямарга гына җитә. Тиешле чара күрелмәсә, тагын 7–10 елдан торбалар тузачак», – дип сөйләде ул.

Халыкны борчыган тагын бер мәсьәлә: республикада торак йортларга кадәр бушлай газ тоташтыру программасының (догазификация) үтәлеше. Билгеле булганча, әлеге программа кысасында газны йортка кадәр китерәләр, ә аны өй эченә кертүне шәхси оешмалар ярдәмендә һәркем үзе хәл итә. Тик халык бу эшнең шактый кыйммәт булуыннан зарлана. Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетында да исәпләп караганнар. «Капкадан өйгә кадәр ара шартлы рәвештә 22 метр дип алсак, корыч, полиэтилен торбаларны, краннарны да исәпкә алып, газны плитәгә тоташтыру 35 мең сумга төшә», – ди Александр Груничев. Кәгазьдәге саннар белән чынбарлык арасындагы «упкын»ны тикшерергә вәгъдә иттеләр.

Алга таба сыек көнкүреш калдыкларын чыгару эшен дә җайга салмакчылар. Татарстан Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты җитәкчесе Александр Тыгин сүзләренә караганда, республика депутатларының бу мәсьәләгә бәйле тәкъдимен илнең 35 төбәгендә хуплаганнар инде. Сүз сыек көнкүреш калдыклары чыгаруга тариф булдыру, транспорт белән алып китүне тәэмин итү, чистарту һәм утильләштерү турында бара. Әлегә исә бу – шәхси йортта яшәүчеләрнең үз баш бәласе.

Кыйммәтле коммуналь түләү кәгазьләре «күләгә»сендә калган тагын бер яңалык – җәмәгать транспортында йөрүгә бәяләр арту турында да сүз булды. 10 гыйнвардан юл билеты өчен банк картасы яки транспорт картасы белән түләгәндә юл бәясе 4 сумга артты һәм 35 сумга җитте. Александр Груничев исә иртәгәге көн турында да уйлый башларга киңәш итте. Бигрәк тә, тимер юл һәм елга транспортына бәйле мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк. Тимерне кызуында сугып, коллегиядә катнашкан Татарстан Премьер-министры Александр Песошин Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына республиканың транспорт тармагын үстерү концепциясен төзергә кушты.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Ышаныч аклансын

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның журналистлар белән традицион очрашуында яңгыраган төп фикерләрнең берсе бу. Очрашу, елдагыча, 13 гыйнвар – Россия матбугаты көнендә узды.

Фикер алышу өчен урын елына туры китереп сайланган иде. 2023 ел республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителгәнгә күрә, бу юлы Татарстан журналистлары Казан халык сәнгате һөнәрчелеге техникумына җыелды. Парламент Рәисе белән очрашуга кадәр, төрле остаханәләрдә катнашып, яңа кәсепләр үзләштерү мөмкинлеге бар иде. Бәйрәм булгач, язу-сызу эшеннән бераз булса да ял итсеннәр, дигәннәр, ахры.

Шуннан соң журналистларны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев котлады.

Фәрит Мөхәммәтшин исә сүзен матбугат хезмәткәрләренә рәхмәт әйтүдән башлады.

– Безнең бүгенге очрашуыбыз матур бер традициягә әйләнде. Республика җитәкчелеге исеменнән сезне бәйрәмегез белән котлыйм һәм зур рәхмәтемне җиткерәм. Без шактый катлаулы чорда яшибез. Әмма горурланып шуны әйтә алам: Татарстан журналистикасы замананың катлаулы сынауларына бирешми, аларга лаеклы рәвештә җавап бирә, – диде ул. – Ветераннарыбызга аерым рәхмәт. Мин сезнең алда баш иям! Риман Гыйлемханов, Габделбәр Ризванов, Любовь Агеева, Мөнир Әһлиуллин, Александр Малов, Тәүфикъ Сәгыйтов, Фәрит Гобәев, Әгъзәм Фәйзрахманов, сез – яшь буын журналистларына безнең күркәм традицияләребезне тапшыручылар, Татарстан журналистикасының «алтын фонды»!

Парламент Рәисе бүгенге җәмгыятьтә журналистларга карата ышанычның югары дәрәҗәдә булуын искәртте.

– Сез бу ышанычны акларга тиеш. Дөньядагы соңгы вакыйгаларга бәйле рәвештә массакүләм мәгълүмат чараларының иҗтимагый-сәяси кырдагы роле тагын да артты. Шуның белән бер рәттән җиткерелә торган мәгълүмат өчен җаваплылык хисе дә артырга тиеш, – диде Мөхәммәтшин. – Мәгълүмати каршылык кискенләшкән чорда укучыга яңалык агымын «кичеп» чыгарга ярдәм итү мөһим. Бу бурычны сездән кала берәү дә башкара алмый.

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренчә, журналистларның тагын бер мөһим бурычы – традицион кыйммәтләр турында күбрәк сөйләү. Ул әлеге мәсьәләнең узган елгы Президент Юлламасында да күтәрелүен искәртте.

Шуннан соң ул басма матбугат вәкилләрен борчыган мәсьәләгә тукталды. Икенче яртыеллыкта газета-журналлар гомуми тиражының сигез процентка диярлек кимүе турында әйтте. «Шулай да, Татарстанның басма матбугаты илдә иң көчлеләр рәтендә кала бирә», – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

САКЛАНУ АРТЫК ТҮГЕЛ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстандагы хәлләргә килгәндә, республикада яңа елның беренче атнасында грипп һәм ОРВИ белән чирләүчеләр саны 12672гә җиткән. Узган атналар белән чагыштырганда, бу – 20,9 процентка кимрәк сан.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, чирләр арасында грипп өстенлек итә. Гыйнвар азагы – февраль башында авыру очраклары тагын да артыр дигән фараз да бар.

Онытыла башлаган коронавирус та үзе турында кабат искә төшерде. «Кракен» дигән штаммы турында кисәтә белгечләр. Анысын да, куркыныч, диләр. Казан федераль университетының Фундаменталь медицина һәм биология институтының прецизион һәм регенератив медицина фәнни-клиник үзәге директоры Альберт Ризванов бу җәһәттән аңлатма бирде.

– «Кракен» – «омикрон»ның чираттагы бер төре, ул аның ике штаммы кушылуыннан барлыкка килгән. Ул коронавирус инфекциясенең иң йогышлы төре булып санала. Баштарак коронавирусны йогышлылыгы буенча грипп һәм кызамык белән чагыштырган булсалар, хәзер инфекция күрсәткечө барлык башка авырулардан да өстен чыкты, – ди белгеч.

Альберт Ризванов вакцинация һәм ревакцинация мәсьәләсенә дә җитди карарга куша. «Спутник V» – саклану өчен бер дигәннәрдән.

ЧҮПНЕ БУРАН СЕБЕРМИ

Чүп мәсьәләсенең ел дәвамында тынып торганы юк. Юллары кардан чистартылып, вакытында тәртипкә китерелеп торган авыллар моның авырлыгын сизми дә. Шул ук вакытта буранлап тору, техника булмау сәбәпле, кайбер авылларга чүп җыючылар барып җитә алмый. Андыйларга нишләргә?

vk.com

Зур Кукмара авылында 2500 кеше яши. Кешесе күп булган җирдә чүбе дә күп була бит инде дип, аларның да хәлен белешәсе иттек. Биредә чүпне ике атнага бер тапкыр җыялар, тик юллар булмау сәбәпле, берничә хуҗалыкка кадәр уза алмыйлар икән.

– Авылның ике башында да яңа йортлар бар. Чүп җыючылар язын-көзен, кышын менә шуларга кадәр кереп җитә алмый. Чөнки анда юл юк, – дип аңлатты авыл советы башлыгы Ришат Хәнәфиев. – Әлеге участокларда яшәүчеләр каты көнкүреш калдыкларын үзәк урамга үзләре алып чыгарга мәҗбүр. Яки үзләре машиналарына куеп алып китеп ташлый.

Кышын бит әле юлларын да карап, чистартып торырга кирәк. Суыгы да, бураны да була, тракторы да ватылмый тормый.

– Бүген һава торышы тыныч, буран юк, тик барыбер кайбер урамнарга кереп булмый. Чөнки карны җил себереп тора, керсәң, чыгып булмаска мөмкин. Шуңа күрә кышын юллар – иң күп игътибар сорый торган тармак. Чүпкә контейнер куйдыру буенча да тәкъдимнәр булган иде, тик мин аны кирәксенмим. Мәшәкате генә артачак. Авылны чүп оясы ясауга каршы мин, – диде Ришат Хәнәфиев.

Моннан тыш, чүпне атна саен җыйсалар да яхшы булыр иде, ди авыл халкы. Тик шул ук вакытта бәясе күтәрелүне барлык кеше дә аңлап бетермәскә мөмкин.

– Агач ботаклары, бәрәңге сабаклары ише әйберләрне җыймый башлаулары да авыл өчен начар булды. Элек бу эшне авыл советы башкара иде. Хәзер кемдер яндыра, кемдер яр кырыена илтеп түгә. Агач ботагына чүпнең башкасы да ияреп килә бит инде, – диде ул.

Көзен Әгерҗе районының Яңа Бәзәкә авылында юллар начар булу сәбәпле, машиналарның ни керә, ни чыга алмый азаплануын язган идек. Кышын чүп алып китү мәсьәләсен дә белештек. Шөкер, кышын авылга керү-чыгу белән проблемалар юк икән. Карны вакытында эттереп, көрәп торалар. Чүп җыючы машина да, ике атнага бер тапкыр килеп, халыкның капчык белән чыгарып куйган чүпләрен алып китә.

– Сукбай этләр күп булган авылларга гына авыррак. Анда чүп җыючыларга хайваннар туздырган пакетларны, калдыкларны үзләренә җыярга туры килә. Бездә андый авырлык юк, – диде Фирдәвес Уразманов.

Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында да халыктан чүп җыю яхшы оештырылган. Биредә чүпне һәр шимбә көнне җыеп алалар.

– Юллар көн саен чистартылып, кардан ачылып тора. Проблемалар булганы юк. Һәр атнаның шимбәсендә килеп җыялар. Контейнерлар кую турында фикер алышулар булган иде, без һәркем көнендә капчыклап чыгарса яхшырак булыр, дигән нәтиҗәгә килдек, – диде Алия Шәрипова.

Күпчелек авыл халкы чүпләрен капчыкка салып чыгарса, контейнерлар куйдырган авыллар да бар. Әйтик, Әлки районының Карга авылында нәкъ менә шулай эшлиләр. Авыл уртача зурлыкта. Бәлки шуңа күрәдер, чүпне атнага бер тапкыр гына алып китсәләр дә, авылда теләсә кайда чәчелеп яткан чүп юк, ди биредә яшәүчеләр.

– Өч ел элек чүп чыгарыр өчен авылга унсигез евроконтейнер урнаштырдык. Тугыз урамда икешәр контейнер тора. Аларны үзара салым акчасына алган идек, мәйданчыкларын да шул хисаптан ясаттык. Мин 32 ел авыл советында эшлим. Шул еллар эчендә чүп мәсьәләсендә иң дөрес карар шушы булгандыр, дип саныйм. Чөнки өч елда авыл чүпкә баткан булыр иде инде. Аңа кадәр бөтен калдык-постык авыл читенә, чокыр-чакырларга чыга иде. Бер атна эчендә контейнер тулып, чүп-чары читкә таралып ятканы юк, – диде авыл советы башлыгы Рамил Минһаҗев.

Үзләре авылда яшәмәсәләр, чүп чыгармасалар да, йортта теркәлгән кешеләрдән акча түләттерү проблемасы турында да әледән-әле ишетеп торырга туры килә. Үлгән кешеләр исеменә түләү кәгазьләре килгән очраклар еш була икән. Аларын да тиешле органнарга хәбәр итеп, вакытында хәл итеп барырга кирәклеген әйттеләр.

– Үзләре читтә яшәсәләр дә, авылда теркәлгән кешеләргә чүп өчен түләү килә. Бик күпләргә кагыла бу мәсьәлә. Безгә шактый мәшәкать тудыра торган хәл. Андый кешеләр ике җирдә чүп өчен түләргә тиеш булып чыга. Мәсәлән, буш йортта теркәлгән кешенең барлык гаилә әгъзаларына килгән очраклар да булды. Андыйлар 18–20шәр мең түләргә тиеш булды. Хатлар яза-яза, көч-хәл белән бер кешегә калдырттык, – диде Рамил Минһаҗев.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

БЕРЕНЧЕЛӘРЕ, СОҢГЫСЫ ТҮГЕЛ

Әссәламегаләйкем вә бәрәкәтүһү!

Казан шәһәренең Совет районындагы Чабакса бистәсендә «Мөгаллим Шәриф» мәчете ачылуга – 10 ел. Мәчетне заманында Буа төбәгендә балаларга белем биргән әтиләре истәлегенә балалары төзеткән. Башлап йөрүчесе республикага мәгълүм шәхес – Марс Шәриф улы Алиев.

Мәчет янәшәсендә «Ислам дине үзәге» дә ачылды. Үзәктә узган елның 1 сентябреннән мәдрәсә эшли башлады. Мәдрәсәдә якшәмбе көнне балалар дини белем ала. Гарәпчә укырга, Коръән сүрәләрен яттан сөйләргә өйрәнәләр. Инде уңышларыбыз да бар, әле күптән түгел генә балалар арасында бәйге дә үткәрелде, малайлар азан әйтүдә, кыз балалар Коръән сүрәләрен яттан сөйләүдә көч сынашты. Бөегебез Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре болай дигән: «Өч нәрсә диндә юк, әмма алар динне саклый. Алар – туган тел, милли кием һәм әби-бабайлардан калган гореф-гадәт».

Шуны истә тотып, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсә шәкертләре Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырен, икенче бер шәкерт пәйгамбәребез турында вәгазь сөйләде. Бәйге Коръән аятьләре уку белән башланды. Бәйгене оештыруда зур булышлыгы өчен «Казанские стальные профили» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Илдар Гыйльфан улы Ногмановка, мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншинга зур рәхмәт! Бәйге исә балалар күңелендә мәңгегә урын алыр, һич онытылмас, дип өметләнәм, ул шулай булачак та. Хөрмәтле милләттәшләр, Сезнең хөкемгә тәкъдим

ителәә торган фото да шуңа булышлык итәр, анда өлкәннәр янәшәсендә – бәйгедә җиңү яулаган балалар.

Гыйнвар ае башларында Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырен уку һәм «Ягез әле, егетләр» дип исемләнгән бәйгеләр узды. «Туган тел»не укуда иң элек Марс Шәриф улы үрнәк күрсәтте, аннан Мөнирә ханым Алиева «Туган тел»не җырлап та күрсәтте, балалар аңа кушылып моңландылар, көч-илһам алдылар.

Мин үзем – Алексеевск районының Урта Тигәнәле авылыннан. Заманында безнең авылда өч мәчет булган. Революциядән соң алар эшчәнлеген туктаткан, әмма аңа карап авылдашлар диннән бизмәгән. Гает намазларын кышын кар өстенә сәлам җәеп укыганнары да истә әле. Хәзер исә дини вазгыять шөкер итәрлек. Теләк кенә булсын. Балаларның мәчеткә тартылулары да сөендерә, монда инде әти-әниләрнең дә өлеше зур. Бәйге дәвамында балалары кебек үк аларның да шатланганын-куанганын күрсәгез иде!

Мондый халәт бәйгене оештыручыларга да дәрт-илһам өстәде. Бу бәйгеләр беренчеләре генә. Киләчәктә тагын да күләмлерәкләре, шулай ук онытылмаслыклары, һичшиксез, булачак.

Рөстәм КАСЮКОВ,
«Мөгаллим Шәриф»
мәчете имам-хатыйбы

Мәрьям апа хаты

Архивымны тәртипкә салып утырганда, күзем бер хатка төште. Бик тә истәлекле хат. Мин аны оныткан идем инде. Ул, шулай әйтергә ярасa, минем авылдашым, күренекле җырчы, композитор Мәрьям апа Рахманкулованың үз кулы белән язган хаты. Хәзерге буыннар өчен дә бик кадерле истәлек.

Әнием, радиодан Мәрьям апа җырлый башласа: «Яшь чагында Мәрьям апа кимендә елга бер тапкыр авылга кайтып йөри иде. Ул миннән ун яшь чамасы олы. Аның әнисе безнең шактый ерактан килә торган нәсел-нәсәпкә барып тоташа. Колхоз чыкканчы, алар кайтып-килеп йөриләр иде. Шуннан соң никтер кайтмас булдылар. Алар кайта торган йорт хәзерге Бәйрәм абзыйлар каршында – елга буенда иде. Нәфисәттәйләр белән алар якын туганнар дип беләм. Ә без исә Нәфисәттәйләр белән агай-энеләр булып яшәдек», – дип әйтми калмый иде. Әни сөйләве буенча, мин менә шуларны хәтеремә сеңдереп калдырганмын.

Мәрьям апа хатында әнисенең туган ягы турында бик тә җылы, матур итеп искә ала. Әлеге юлларны укыгач, Мәрьям ханым миңа тагын да якын булып китә. Менә ул хат:

«Кукмара районы, бигрәк тә Арпаяз авылы минем өчен күп кенә хатирәләр белән бәйләнгән, Арпаяз авылы минем бала чакларымны хәтерләтә. Бик күп еллар элек ул авылда яшәгән гаҗәеп күңелле, мөлаем кешеләре күз алдыма килеп басалар.

Арпаяз – минем әниемнең туган авылы. Безне кечкенә чакта җәй саен, сабактан туктагач, әнием Арпаяз авылына алып кайта иде. Җәй буе авыл балалары белән чабышып уйнаулар, борчак кырына барулар минем күңелемдә бик матур эз калдырган. Борчак кырына без, ахры, бик күп йөри башлаганбыз. Олыларның, бу хәлдән безне тыю өчен, кызыклы хәйлә корганнары хәтеремдә. Урамның икенче ягында яшәүче Бәйрәмгали абый, борчак кырына яшерен генә барып, түбәтәен һәм казакиен эчке ягы белән әйләндереп киеп, безнең килгәнне көтеп үсемлек арасында яшеренеп утырган. Без йөгерешеп килеп, бик кызып кына борчак җыярга керешкәч, кинәт кулларын канаттай җәеп, «һау-у-у» дип килеп чыгуы һәм безнең гаять дәрәҗәдә куркышып чабуларыбыз хәзер дә истән чыкмый. Шул хәлдән соң борчак кырына йөрүдән, билгеле, без – вак балалар туктадык.

Авыл астындагы су буйларын, тәмле сулы чишмәләрен хәтерлим.

Су буеның икенче ягында авылга карап биек ялан тау тора иде. Ул таудан без, балалар, көн саен кечкенә арбалар белән тәгәрәп төшеп уйный идек. Башка балаларныкы шикелле шул арбаларны безгә кардәш абыйларыбыз – Салихҗан, Зиннәт абыйларның ясап биргәннәрен хәтерлим. Ул кызыклы арбалар кечкенә генә, ике тәгәрмәчле, ике башында ике тәртәле була иде. Алдан ике тәгәрмәч тәгәрәп, артта ике тәртә өстерәлеп барып, безне текә таудан тәгәрәтеп алып төшүе безнең өчен бик кызыклы иде. Бәйрәмгали абзыйларда бик тәмле сосла эчүләрем дә хәтердә калган.

Кечкенәдән үк мин бик җырны, көйне сөючән идем. Габдулла Тукайның инде гасыр башында ук шигырьләре халык арасында тарала башлаган иде. Мин шул шигырьләрне һәм башка матур халык җырларын калын дәфтәремә теркәп бара идем. Дәфтәрне бер дә үземнән калдырмыйча, җәй көне авылга да алып кайта идем. Авылда хатын-кызлар җыелып, миннән дәфтәрдәге шигырьләрне укыталар һәм җырлаталар иде. Төннәрдә авыл егетләренең су буенда гармун уйнап, авыл көйләрен җырлауларын мин таң атканчы йокламыйча тыңлап бик нык тәэсирләнә идем. Моңлы җырлаудан, гармун тавышыннан күңелем тулып елап ята идем.

Бик кечкенә чактан ук туган халкыбызның иҗади моңы белән сугарылып, халкыбызның искиткеч бай һәм гүзәл җырын-көен үзләштереп үскәнгә күрә, бара торгач, мин турыдан-туры сәнгать дөньясына кереп киттем. Соңыннан инде олы сәнгать кешесе булып китүемә Арпаяз авылының, аның элек-электән талантлы халкының да шактый йогынтысы булды дип саныйм.

Арпаязның тирә-якларын да бераз хәтерлим. Ерак-ерак урманнарга, олыларга ияреп, җиләк җыярга да баргалый идек. Пычак, Өлге авыллары да бераз истә калган.

Хәзерге вакытта халкыбызның тормышы, культурасы зур адымнар белән алга китте, авылларыбыз зур уңышларга ирешт. Авылларның мин кечкенә чактагы надан, фәкыйрь тормыш күренешләре хәзер әллә кайчан күргән бер төш шикелле генә тоела. Авылларыбыз хәзер шәһәрләрдән аермаслык бай, матур яшиләр.

Рахманкулова Мәрьям, РСФСРның халык артисткасы. 11. XII.1979».

Күрәбез, бу хатның язылуына кырык елдан артып киткән. Мәрьям апа аннан соң унөч ел яшәде әле. Хаттан ачык күренгәнчә, бу бөек шәхес, халкыбызның талантлы кызы гомеренең азагына кадәр безнең туган ягыбызга мәхәббәт белән яшәгән, анда күргәннәрен-кичергәннәрен олыгайганчы хәтерендә йөрткән. Аның әйткәннәре горурлык уята.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе нәтиҗәле эшләве өчен Статистика дәүләт федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе **Гатауллина** Татьяна Вячеславовна Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

Шәһәрдә дә – авыл тормышы

Сугыштан соңгы елларда авыл кызлары (исемнәрен үзгәртеп язам) Мәликә белән Нәгыймә апалар да, яшәр өчен, Кукмара районындагы Татар Толлысы авылыннан Казанга юл тотты. Шунда эшләгәндә Мәликә апа – Шакирга, Нәгыймә апа Закирга кияүгә чыгып, матур гына гомер иттеләр. Әни аларны авылга чакырып кунак итә иде. Киткәндә алар үзләре дә бурычлы булып калмый, кунак ашы кара-каршы, дип адресларын язып калдыралар иде.

1960–1970 елларда Казанда укыганда миңа аларда яшәп алырга да насыйп булды. Йорт-җирләре Казан читендәге сазлыклар тирәсендә, үзләре җиткергән өйләрдә яшиләр.

Шакир җизнинең өе иркен: олы ягы, кухнясы, өйалды бар. Ит өчен бозау асрый, тавыклар тота. Бакчасында бәрәңге, төрле яшелчә үсә. Җизни Казансу елгасына балык тотарга да йөри, иптәшкә мине дә ияртә. Бакчада үземә эш табам: чүп утыйм, яшелчәләргә су сибәм. Суны әллә кайдан эзләп йөрисе дә юк: торфлы чокыр тулы. Җизни торфлы, сазлы бакчасын казып, ком тутырып күмә, җирен күтәрә. Кишер түтәлен чүп үләннән керосин сибеп арындыра идек. Монысын лекция вакытында укытучыбыз сөйләгән иде. Мин практикада сынап карадым һәм җизнидән мактау сүзләре ишеттем. «Молодец, укуың гел файдага гына булсын», – диде ул. Мин исә: «Шәһәрдә дә авыл тормышы икән», – дип нәтиҗә ясадым.

Мансур ХӘСӘНОВ

Әле дә истә

Моннан ярты гасыр элек Саба автохуҗалыгында шофер булып эшләгән елларда күп вакытыбыз хуҗалыклардан ит комбинатына мал ташып уза иде. Төрле хәлләр булды: кызыгы да, кызык түгеле дә, хәзер менә шулар хәтердә яңара.

Шулай бер елны кышкы буранда «Большевик» колхозыннан Казанга бару өчен юлга чыктык. Машиналарга дуңгызлар төялгән. Мин артта барам. Ни күрим: миннән алда бара торган машинадан бер дуңгыз төшеп калды. Мин бата-чума дуңгызны куып-тотып, көч-хәл белән кабинага өстерәп керттем дә юлны дәвам иттек, аннан ит комбинатына тапшырдык. Бер тапкыр баруыбызда минем машинадан да дуңгыз төшеп калган булып чыкты.

Үткән гасырның алтмышынчы еллары азагында безне Чүпрәле районына чөгендер ташырга җибәрделәр. Район басулары бик уңдырышлы, кара туфраклы иде. Уңыш та мулдан җыелган. Аннары кабат үзебезнең төбәккә кайтып, ит комбинатына дуңгызлар илтү эшенә керештек.

Шулай беркөнне Әбдегә барып, ап-ак 20 баш дуңгыз төяп, Шәмәрдәнгә ит комбинатына килеп җитеп дуңгызларны бушаттым да сәерсенеп карап торам. Дуңгызлар… кап-кара. Соңыннан төшендем инде: Чүпрәледә чем-кара туфрак ич, машинаның кузовын юарга кирәклеге искә дә кермәгән.

Габделәхәт ШАКИРОВ.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе,

әнисе

кинәт вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Моратов Марат Яшәр улының авыр кайгысын уртаклаша.

КҮҢЕЛЛЕ ВӘ ФАЙДАЛЫ СӘФӘР

Әниләр көне уңаеннан, әниләргә хөрмәт йөзеннән, «Тылсым» халыкка комплекслы социаль ярдәм күрсәтү үзәгеннән автобус биреп, бер төркем «көмеш» яшьтәге волонтерларны экскурсиягә чакырдылар. Ә экскурсия Купка авылындагы «Кукмара сөте» комбинатына һәм Аш-Буҗи авылындагы камыр ризыклары һәм икмәк пешерү цехына иде.

Үземнең дә ул якларга барып, шушы алдынгы, мактауга лаек комбинатларны, анда хезмәт куючыларны күрәсем килгән иде. Теләгем тормышка ашты.

Иң беренче шуны аңлатып үтим: «көмеш» яшьтәге волонтерлар – әлбәттә, пенсия яшендәгеләр. Тормыштан ямь табып, бүгенге көннең, тормышның матурлыгына сөенеп яшәүчеләр. Алар өлкән яшьтәгеләрнең хәлләрен беләләр, күчтәнәчләр белән сөендерәләр, мөмкинлекләре чикләнгән балалар йөри торган үзәктәге балаларны сыйлыйлар. Һәр атнаның җомга көнендә «Тылсым» үзәгенә йөрүче балаларны кул эшләренә өйрәтәләр.

Безне социаль хезмәткәр – мөлаем Гөлия туташ Мәхмүтова озатып йөрде.

Менә Аш-Буҗидагы камыр ризыклары пешерү комбинаты. Монда 14 төрле тәм-том пешә икән.

Эшләр күбесенчә автоматлаштырылган. Билгеле, кул белән генә эшләүчеләр дә бар. Без хәйраннар калып күзәтеп йөрдек. Алар мастер-класслар да үткәрделәр. Монда мин үземә бер ачыш ясадым. Каймак пирогы камырын табага җәйгәч, ничек итеп бөгәргә икәнлеген тәгаен генә белми идем. Ә мондагы кызлар өйрәттеләр. Самса камыры да ясарга өйрәндек.

Монда тортларның да ниндиләре генә юк. Искитәрлек тәмле ризыкларны 64 кеше пешерә. Менә бит күпме кеше эшле булган. Барыбыз да ризыкларын күп итеп сатып алдык.

Эшчеләрне иртән машина килеп ала, эш сәгате тәмамлангач, өйләренә илтеп куя. Хезмәт хакын мулдан түлиләр. «Эшләгәнебезнең рәхәтен күреп яшибез», – ди кызлар. Мондый күренекле җирдә эшләү – үзе бер дәрәҗә бит. Бар кешегә дә тәтеми бит әле мондый эш. Мәсәлән: ике комбинатта 100гә якын кеше эшли икән, димәк, 100 гаилә финанс ягыннан тәэмин ителгән дигән сүз.

Купка авылындагы «Кукмара сөте» комбинатына килеп кергәндә, бу тирә әчегән сөт исе белән тулгандыр, дип уйлый идем. Нык ялгышканмын икән. Биредә дә чисталык хөкем сөрә.

Безне сөт комбинаты технологы Нурия каршы алды. Идәннәр чип-чиста итеп юылган. Барлык төр җиһазлар күгәрми торган металлдан эшләнгән, ялтырап торалар. Майның ничек язылуын, эремчекнең ничек ясалуын, безнең гаилә яратып эчә торган «топленое молоко» сөтенең кайда кайнатылуын, каймакның ничек тутырылуын үз күзләребез белән күрдек. Әллә кайдан кайткан түгел бит, барысы да үзебезнеке.

Сөт ризыгы белән көн саен 5–6 машина

районыбызның төрле авылларына, Киров өлкәсенә, Мамадыш якларына чыгып китә икән.

Шушы буш кырда, тәвәккәлләп, шушындый җитди эшкә алынган кешеләргә афәрин диясе генә кала.

Аларның эшли башлауларына – 4 ел. Шушы вакыт эчендә эшчеләр дә нык остарган. Җитештерә торган ризыкларының да сыйфаты яхшыра гына бара. Без экскурсиядән бик сөенеп кайттык. Аны оештыручыларга рәхмәтебез чиксез, һич онытылмаслык сәфәр булды ул. Күңелләребез дә баеды, тәмле ризык пешерү серләренә дә төшендек. Елларыбыз тыныч булып, һәр туар таңга сөенеп яшәргә язсын.

Рафилә ФӘТТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

15 гыйнварда кадерле әтиебез, дәү әтиебез, туганыбыз һәм дустыбыз **НАСЫЙБУЛЛИН Шәйхулла Галимулла** улы үзенең 75 яшьлек гомер бәйрәмен билгеләп үтә. Җанын һәм рухын гыйнвар суыклары да туңдырмаган, ләкин гыйнвар аеның аклыгын һәм сафлыгын күңелендә саклаган, тормыш юлын башкаларга үрнәк булырлык итеп үткән якын кешебезне чын күңелдән юбилее белән котлыйбыз. Аңа сәламәтлек, җан тынычлыгы белән гомер итүен телибез!

1948 елда Питрәч районының Салкын Чишмә дип аталган бик матур авылында дөньяга килә әтиебез. Беренче хезмәт адымнары да, соңгылары да туган җире – Питрәче белән бәйле аның. Ленино-Кокушкино урта мәктәбен тәмамлаган егет гади балта остасы булып эшли башлый. Аннары Казан төзүче мастерлар мәктәбен тәмамлый һәм кабат «Ленино-Кокушкино» совхозына мастер булып эшкә кайта. Югары белем ала. Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. Хезмәт сөючән, таләпчән хезмәткәрне җитәкчелек тиз күреп ала. 5 ел шушы ук совхозны җитәкли, алга таба районның төрле төзелеш һәм авыл хуҗалыгы оешмаларында җитәкче урыннарны били Шәйхулла Галимулла улы.

Республика җитәкчелеге дә оста оештыручыны, алга карап эш итә торган җитәкчене күз уңыннан ычкындырмый. Берара Биектау районында Коркачык төзелеш производствосы комбинатында директор булып эшләгәннән соң, Биектау районы хакимияте башлыгының беренче урынбасары итеп билгеләнә. Алга таба һәр эшен җиренә җиткереп башкаручы җитәкчене үз туган ягына – Питрәчкә район хакимияте башлыгы итеп билгелиләр.

Үз туган ягын үстерүгә зур көч куйган кеше буларак, аны хөрмәт итәләр. Киңәшен, бай тормыш тәҗрибәсен яшьләр белән дә бик теләп уртаклаша. Ир буларак хатынына – терәк, балаларына, туганнарына олы киңәшче булып тора. Дусларны санлый белә, кирәктә ярдәм итә торган кеше ул. Балаларын, оныкларын гади һәм гадел яшәргә өнди.

Республикабызның төзелеш һәм авыл хуҗалыгы үсешенә керткән олы хезмәтләре өчен әтиебез дәүләтебезнең югары бүләкләренә, дәрәҗәле исемнәргә лаек булды.

Бәхетле картлык, гаилә иминлеге телибез. Хөрмәткә коенып, тигезлектә яшәргә язсын сиңа, кадерле кешебез!

Иң җылы теләкләр белән, хатының, балаларың, оныкларың, туганнарың һәм дусларың

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Курку

Куркаклык ул бертөрле генә булмый. Бер мәлне бер дус белән мунча керергә киттек. Шулай туры килде инде: ирләр – аерым, хатыннар аерым керә. Көз. Төн. Караңгы. Пычрак. Аякларга пычрак ияләтмәскә теләп кенә бер ун минут барганбыздыр ул мунчага. Бардык. Кердек. Утны яндырдык. Һәм кинәт ут сүнде. Ә мин – Ходайның шайтан шаярткан бәндәсе. Кинәт кенә сулыш аша гына тегенең исемен пышылдадым. Бу кинәт дөньясын онытты:

– Туктале, миңа кемдер дәшә бит, – ди.

– Кит әле, – мәйтәм, – ут сүнгәнгә дә шулай җебеп торма әле.

Ә үзем кабат сулыш аша гына пышылдыйм:

– Ә-ә-ә б-би-и-т мин сине көттем...

– Син ишеттеңме?! – ди дустым. – Ул мине көттем ди.

– Юк инде, – мәйтәм. – Монда нәрсә ишетәсең? Китер әле тәмәкене...

Тәмәке дә, теге дә юк. Мунча өйалдының ишеге генә селкенеп тора. Артыннан киттем. Ну, килгәндә озак килдек бит инде. Кайтуы тиз икән. Минут эчендә кайтып җиткән дә өй ишеген ачалмыйча калтыранып тора.

– Ярый, тынычлан, зинһар, – дим. – Мин пышылдадым.

Теге ышанып җитми. Пышылдап күрсәтергә туры килде.

– Ә-ә-ә б-би-и-т мин сине көттем...

Шул рәвешле тынычланып кына бетте, дигәндә... Безнең бер дус тәмәке тартырга чыккан да сөйләшүебезне тыңлап торган. Хәлне аңлаган инде бу.

Тегене тынычландырып, ишекне ачып, верандага керсәк – пышылдау тавышы. Теге дусның исемен атыйлар. Бу юлы хәтта мин дә куркып киттем. Икебез дә тынып калдык. Колак салып торабыз. Нәкъ мин бая пышылдаган кебек:

– Ә-ә-ә б-би-и-т мин сине көттем...

Теге дус хәзер чат ябышты миңа. Берничек тә ычкындырып алырлык түгел. Ә тавыш кабатлана...

Ярый әле веранда эчендә ут янды. Шунда гына авызы колагына җиткән икенче бер дусны күрдек. Тынычландык инде икебез дә.

Көлешкән булдык.

Ә бер карасаң, кешене куркытудан да җиңелрәк нәрсә юк икән. Моның өчен зур-зур сугышлар да, афәт-фаҗигаләр дә мөһим түгел. Моның өчен нибары бер куркак һәм ике ахмак җитә.

«АЛТЫНЫМ» ДИП ДӘШӘ ИДЕ

ТАТАРСТАН ҺӘМ РОССИЯНЕҢ ХАЛЫК АРТИСТЫ ФУАТ МАНСУРОВ ИСЕМЕ ҮЗЕ ЯШӘГӘН ЙОРТТА МӘҢГЕЛӘШТЕРЕЛДЕ

«Татар-информ»

Атаклы дирижерның кызы Марина Мансурова атасы турында хатирәне саклаулары өчен олы рәхмәтен белдерде.

Искә алу

Музыкант та, альпинист та, шахматчы, математик, дирижер да. Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова Фуат МАНСУРОВНЫ күпкырлы шәхес дип атады.

– Чыннан да, бүген – тарихи вакыйга. Без моңа шактый озак килдек һәм, ниһаять, Фуат Шакирович яшәгән бинада аның истәлегенә мемориаль такта ачылды. Ул бар яктан да талантлы шәхес иде. Физика-математика юнәлеше буенча уку йортын тәмамлаганнан соң, ул күпмедер вакыт университетта укыткан. Тик соңыннан янәдән музыка сәнгатенә кайткан. Үз чорының иң якты һәм кызыклы кешеләрен үз янына җыйган һәм сәнгатебезне алга этәргән бөек шәхесебез, – диде тантанада мәдәният министры. – Фуат Мансуров 20 елдан артык Зур театрда дирижер булып эшләде, милли әсәрләребезне Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрына алып керде, симфоник оркестрыбызга яңа тормыш, энергия бирде. Минемчә, милләтнең һәм халыкның бәхете мондый балалары булуда гына түгел, аларны хәтерләүдә дә. Шуңа күрә бүгеннән күренекле шәхесебезнең 100 еллыгын билгеләп үтүгә әзерлек эшләре башлана. Аның традицияләрен дәвам итүчеләр өчен яңа конкурс, премия, стипендияләр булыр дип ышанам. Ул музыка мәдәнияте яшәсен өчен бик күп эш башкарган. Әлеге эш алга таба да дәвам итәргә тиеш.

Намусы кушканча эшләде һәм үзеннән соң зур эз калдырды. Татарстан Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин музыкант турында шулай диде.

– Мин аның белән шәхсән таныш булу бәхетенә ирештем. Ул Татарстан дәүләт симфоник оркестрының баш дирижеры булып эшләгәндә, ярты ел саен Татарстан композиторларының әсәрләреннән торган концертлар оештырылды. Әсәрләрне сайлап алуга ул бик игътибар белән карый иде, яшь композиторларга киңәшләрен бирә, үз төзәтмәләрен кертә, кирәк чакта тәнкыйтьли дә ала иде. Аның татар милли мәдәниятенә керткән өлеше бәяләп бетергесез, – диде ул.

Таләпчән музыкант иде. Казан шәһәре Башкарма комитетының мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов Фуат Мансуровны шулай дип искә алды.

– Беренче чиратта үзенә, оркестр артистларына таләпчән булды. Репетицияләрдә, чыгышларында һәрвакыт әзерлекле иде. Фуат Мансуров – барыбызга да үрнәк шәхес. Мәскәүдәге Зур театрда аның катнашында куелган «Пәтша кәләше» спектакле һаман да эталон булып санала. Һәм мондый мисаллар бик күп. Татарстанның дәүләтчелеген, республика гимнын булдыруга зур өлеш кертте. Ритмга, темпка аеруча игътибарлы иде. Ул һәрвакыт музыка һәм математика арасында уртаклыкны таба иде. Хәтерлим, әле ул вакытта консерватория студенты чагым, зур концерт залы сәхнә артында: «Математиканы үзләштермәсәң, музыканы үзләштермәячәксең. Чөнки музыка ул – математика», – диде. Бу сүзләрне мин гомерем буена истә калдырдым.

Татарстан, Казан бүгенге заманның шундый күренекле музыканты булу бәхетенә ия. Маэстрога лаеклы истәлек тактасы ясаган скульптор алдында баш иям, – диде Азат Абзалов.

Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе профессоры Ринат Халитов опера юнәлеше буенча профессиональ белгечләр әзерләүдә Фуат Мансуровның роле зур булуын искәртте.

– Һичшиксез, опера һәм симфоник оркестр дирижерлары конкурсы аның исемен йөртергә тиеш, – диде профессор.

Татарстанның атказанган артисты, Казан дәүләт консерваториясе профессоры Илсур Айнатуллов күренекле дирижер белән бергә эшләгән елларын искә алды.

– Мәскәүдә укып кайткач, 1988 елда ул мине оркестрга эшкә алды. Студентларга «алтыным» дип эндәшә иде. Без – татар егетләре белән татарча сөйләшергә ярата. Гастрольләр белән кая гына барсак та, укучылары аны рәхмәт әйтеп каршы ала иде. Фуат Шакирович полиглот та иде әле. Франциягә барсак – французча, Германиядә – немецча, инглизчә сөйләшә иде.

Фуат Мансуровның кызы Марина Мансурова әтисен шаян, шул ук вакытта җитди кеше иде, дип искә алды.

– Әти турында бик күп сөйләргә була. 79 яшендә әти авырып алды. Краснодарда аңа операция ясадылар, аннан соң ул озак тернәкләнде. Хастаханәдә ятканда миңа шалтыратты да: «Марина, мин әле исән!», – диде. Аның чыдамлыгына һәм эшкә тугры булуына мин һәрвакыт гаҗәпләнеп һәм сокланып яшәдем. Юморны бик ярата иде. Әтигә багышлап шундый истәлек куелуга мин бик рәхмәтле. Без аны хәтеребездә саклап яшәрбез дип ышанам, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

КИТАБЫН ТОТЫП КАЙТТЫ ТУГАН ЯГЫНА

ЮЛСУБИНОДА РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН САЛОН-МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ

Шәхесләребез

«Шагыйрь булып, китабыңны тотып, кайтсаң иде туган ягыңа!..» – дип язган булган Равил Фәйзуллин яшь чагында. Бер уйласаң, берничә гади генә сүз бер җөмләгә тезелгән, ә нинди зур мәгънә, нинди зур фәлсәфә!

12 гыйнварда Балык Бистәсе районы Юлсубино (Балтач) авылында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинга багышланган музей ачылды. Гадәттә, музейны бакыйлыкка күчкән шәхескә атап ачалар. «Тереләргә атап музей ачарга кирәк», – диде язучының адашы һәм якташы, РСФСРның халык артисты Равил Шәрәфиев. Бу нисбәттән әлеге музейны салон-музей дип атарга карар кылганнар. Беренчедән, ул Равил Фәйзуллин иҗатын гына түгел, ә шушы район җирлегеннән чыгып, дөньякүләм танылу алган әдәбият-сәнгать әһелләре иҗатын да колачлый. Икенчедән, Равил абый әйтүенчә, бу төрле очрашулар оештыру урыны, кайнап торган җир булырга тиеш.

Музей ачылышы бәйрәм кебек оештырылган иде. Кунакларны гармун-баяннар белән каршы алдылар. Казаннан, Түбән Камадан, башка яклардан бик күп кунаклар кайткан. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, «Татмедиа» агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, Балык Бистәсе районы хакимияте башлыгы Радик Исламов, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстан Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм күрсәтү фондының башкарма директоры Нурия Һашимова музей ачылышы уңаеннан җылы сүзләрен җиткерделәр.

Берара очрашу Равил Фәйзуллин юбилеена әйләнә башлады, моны «юбиляр» үзе дә шаярып төрттереп куйды. Язучы Зиннур Мансуров яшь Равилнең әдәбиятка яңалык алып килүен кырмыска оясына тыккан таяк белән чагыштырды. Бунтарьлык мәктәптән үк килгән. Класс җитәкчесе староста Равилгә характеристика язганда болай дигән: «сыйныфта тәртип урнаштыра алмады, әмма бөтен классны үз җаена борды».

«Татар-информ»

Балачагын Равил ага үзе дә көлеп искә ала. Өченче сыйныфта укыганда редакциягә шигырь җибәргән ул һәм үзенең биографиясен дә теркәп куйган. «Узган чирекне гел «бишле»гә тәмамладым, ә бу чиректә бер «дүртле»м чыкты, әмма мин аны, һичшиксез, төзәтәчәкмен!» – дип тәмамлаган ул «биография»не.

Җәлил хәзрәт Фазлыевның шушы очрашуда әйткән бер сүзе истә калды. «Мәктәпләребез музейга әйләнмәсен иде», – диде ул. Моңа капма-каршы фикер дә әйтелде: бүгенге музей ачылышы – киресенчә, мәктәпне саклап калу омтылышы ул. Моны Равил абый үзе дә кычкырып ук әйтмәсә дә, үзара сөйләшкәндә аңларлык итә. Бүген зур гына Юлсубино мәктәбендә нибары 25 бала укый. Фәлән авылда фәлән бала, төгән авылда – төгән. Кайдадыр, гомумән, мәктәп ишеге бикле, ә балаларны күрше авылга автобус йөртә. Эш музейда түгел. Авыл мәктәпләреннән алга таба Равил Фәйзуллиннар чыгармы? Менә бит нидә хикмәт. Гомумән, калырмы авылда мәктәп? Калырмы мәктәп баласы? «Шагыйрь булып, китабыңны тотып, кайтсаң иде туган ягыңа!..» – дип хыялланган авыл баласы?

Данил СӘФӘРОВ

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5302 данә
Гомуми тираж – 15536 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 205

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+